РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 ноябрь, 2020 ел    Кукмара ш.    № 26

«2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль район Советының 2019 елның 13 декабрендәге 258 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Кукмара муниципаль район Советы **карар бирде:**

«2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль район Советының 2019 елның 13 декабрендәге 258 номерлы карарының 17.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$17^{1}$. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән һәм Кукмара муниципаль районының муниципаль милкен (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән һәм аны бирү законнар белән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән җир кишәрлекләрен арендалаучы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына 2020 елның 1 апреленнән 1 октябренә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен кичектереп тору яисә 2020 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен түләүдән азату бирелә.

Кукмара муниципаль районының муниципаль милкен (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән һәм аны бирү законнар белән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән җир кишәрлекләрен арендалаучы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга 2020 елның 1 апреленнән 1 октябренә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен кичектереп тору яисә 2020 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен түләүдән азату бирелә.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булып торучы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләре

хуҗаларына 2020 елның 1 апреленнән 1 октябренә кадәр реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүләрен кичектереп тору бирелә.

Аренда түләүләрен һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләр түләүне кичектереп тору шартлары һәм сроклары, аренда түләүләреннән азат итү шартлары Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль район Советының аерым карары нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль милкен (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән һәм аны бирү законнар белән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән җир кишәрлекләрен арендалаучылар һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләре хуҗалары 2020 елның 1 апреленнән 30 сентябрен дә кертеп, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының аерым карарында каралган тәртиптә һәм шартларда реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен аренда түләүләре һәм түләүләр кертү буенча бурычларны үтәмәгәндә (тиешенчә үтәмәгәндә) җаваплылык чаралары кулланылмый.».

Район Башлыгы С. Д. Димитриев